# Россия - минем туган илем



# Максат:

- Туган якның тарихы белән танышу, матурлыкларын күрергә һәм аны бәяләргә өйрәнү;
- туган төбәктә яшәүче халыкка карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү.



# Россия картасы




17 млн.км$^2$

# Бэрәңге районының картасы



Халык телендә йөргән риваятьләргә караганда, Бәрәңге авылына Чураш һәм Бураш исемле татарлар нигез салган. 1699 елда телгә алына. 1931 – 1932 - Татар районы дип йөртелә. Шунан сон ул хәзерге исемен ала.







Сорасагыз әгәр…

Туган илең кайдан башлана дип,
Сорасагыз әгәр сез миннән.
Әйтәм:
Башлана ул авылымның,
Мин дөньяга килгән өемннән.
Башлана ул авылым урамыннан,
Якындагы иген кырыннан.
Борчак тарткан иген басуыннан,
Печән чапкан яшел болыннан.
Балык тоткан елга буйларыннан,
Мин укыган мәктәп юлыннан.
Ат чаптырган сабан туйларыннан,
Суын эчкән чишмә буеннан.
И кадерле, якын туган ягым,
Туган телем мине кеше иткән.
Мине татар иткән туган телем,
Туган илем жандай кадерле!

Әхмәт Рәфиков

Туган ил – туган авылдан, андагы һәр сукмактан, андагы без үткән юлдан башлана икән. Шуңа да үзенең Туган авылы, Туган ягы, Ватаны белән горурланмаган кеше юктыр ул. Кеше туган ягын өзелеп яратканга, башка төбәкләрдән өстен итеп күрәсе килә.

1 нче январь 2018 елга:

172 – хужалык;

518 – кеше яши.

Уен «Янавыл»





-Туган җир, туган авыл, туган як, туган ил? Бу төшенчәләр барысы да бер мәгънә аңлатамы?
- Әйе, бу төшенчәләрнең мәгънәләре бер, тик мәгънә төсмерләре төрле .
- Шулай булгач һәркайсына ачыклык кертеп китик әле.
- Туган авыл дигәндә, үзебез яшәгән авылны күздә тотабыз.
- Туган җир ул – авылымның табигате, болыннары-кырлары, елгалары-сулары да.
- Ә менә туган як дигәндә мин үзебезнең район территориясен, туган авылыма янәшә торган авылларны күз алдымда тотам.
- Туган ил – ул Ватан. Бу ике төшенчә киңрәк мәгънәгә ия. Россия территориясенә чыкканда, Марий Эл республикасы минем Ватаным. Ә инде чит илгә чыгырга туры килсә, бу очракта Россия территориясе дә минем Ватаным була.

**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!**